ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

# БОЕРЫК

**03.05.2023** **№ 10-07/60**

Казан ш.

2023 елда кулланучыларның
хокукларын яклау темасын
иң яхшы яктырту буенча
республика конкурсын уздыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014-2025 елларга Татарсатан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклауның клмплекслы системасын үстерү ярдәмче программасына кушымтаның 2.12 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1. 2023 елда кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын уздыру турында Нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Татарстан Республикасы журналистлар Союзы-Иҗади союз» региональ җәмәгать оешмасына кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын оештыручылар буларак катнашырга тәкъдим итәргә.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Эчке базарны үстерү һәми координацияләү бүлегенә (Р.М.Арсланова) кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү эшен расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә оештырырга, шулай ук әлеге Боерыкны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенә, «Татарстан Республикасы журналистлар Союзы-Иҗади союз» региональ җәмәгать оешмасының рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары башлыкларына җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2022 елның 4 маендагы 10-07/53 номерлы «2022 елда Кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика конкурсын үткәрү турында»гы боерыгын үз көчен югалткан танырга.

5. Әлеге Боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

6. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Ф.Г.Хамматовка йөкләргә.

**Җитәкче** **Җ.Й.Әхмәтханов**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2023 елның 3 маендагы 10-07/60 номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**2023 елда кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика конкурсын уздыру турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Кулланучыларның хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртуга республика конкурсы (алга таба – Конкурс) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014-2025 елларга Татарсатан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклауның клмплекслы системасын үстерү ярдәмче программасына кушымтаның 2.12 пункты нигезендә үткәрелә.

1.2. Конкурсны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (килешү нигезендә), «Татарстан Республикасы журналистлар Союзы-Иҗади союз» (килешү нигезендә) региональ җәмәгать оешмасы оештыра.

2. 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – массакүләм мәгълүмат чараларын (алга таба – ММЧ) кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрен киң яктыртуга җәлеп итү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

Кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрен пропагандалауга зур өлеш керткән журналистларның иҗади активлыгын бүләкләү;

ММЧда кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрен яктырту алымнарын һәм формаларын камилләштерү;

Кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрендә республика гражданнарын агарту дәрәҗәсен күтәрү.

## 3. Конкурс Номинацияләре

Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә, аларның һәркайсында җиңүче билгеләнә:

«Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча басма массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы публикация»;

«Татарстан Республикасында гражданнарның кулланучылар грамоталылыгын арттыру буенча массакүләм мәгълүмат чараларының иң яхшы редакциясе»;

«Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы интернет-басма»;

«Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы телесюжет (яки телетапшыру)»;

«Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы радиосюжет (радиотапшыру)».

## 4. Конкурста катнашучылар һәм гариза бирүчеләр

4.1. Конкурста Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы тиешле закон тәртибендә теркәлгән Россия Федерациясе ММЧ редакцияләре (алга таба – ММЧ редакцияләре), аерым авторлар, юридик затлар катнаша ала.

4.2. Конкурсның гариза бирүчеләре ММЧ редакцияләре, аерым авторлар, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 5.7 пункты нигезендә документлар пакетын тапшырган юридик затлар (алга таба - Мөрәҗәгать итүчеләр).

Конкурста массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, аерым авторлар, конкурс эшләре әлеге Нигезләмәнең 6.1 - 6.3 пунктлары нигезендә конкурста катнашуга кертелгән юридик затлар (алга таба - Катнашучылар) катнаша.

## 5. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм шартлары

5.1. Конкурс 01.07.2023-18.11.23. кадәр бер этапта үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://gosalcogol.tatar.ru) һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы порталында (https://www.tatzpp.ru) 2023 елның 20 июненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурсны үткәрү шартлары, номинацияләр, шул исәптән конкурс эшләрен бәяләүнең өстәмә өлешен дә кертеп, критерийлары һәм тәртибе, гаризалар кабул итүнең башлануы һәм тәмамлануы, аларны тапшыру тәртибе, бүләкләү күләме һәм формалары, шулай ук конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

5.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә Конкурста катнашу турындагы гаризалар тапшыру срогы 2023 елның 1 июленнән 2023 елның 20 октябренә кадәр.

Гаризалар түбәндәге адрес буенча җибәрелә: 420107, Татарстан Республикасы, Казан ш., Һади Такташ ур., 94, (почта) һәм (яки) электрон почта аша (pdf, jpeg форматларында яки видеоформатта): konkurs.zpp@tatar.ru «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктыртучы Конкурсына» тамгасы белән.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 277-94-99, 277-94-95.

5.3. Конкурска бер генә гариза бирелгән яки бер генә гариза да бирелмәгән очракта, Конкурс гамәлгә ашмаган дип таныла.

5.4. Конкурска әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә күрсәтелгән конкурс

номинацияләре нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә 2022 елның 21 октябреннән 2023 елның 20 октябренә кадәр башкарылган конкурс эшләре тәкъдим ителә.

5.5. Конкурска түбәндәге эшләр кабул ителә::

телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, телесюжетлар цикллары һәм башка телевизион эшләр) MP4 форматында тәкъдим ителгән һәм (яки) CD - яки DVD-дискта, йөкләп алу өчен актив сылтамалар һәм (яки) хәтер флеш-картасында;

радиосюжетлар (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар цикллары) MP4 форматында тәкъдим ителгән һәм (яки) CD - яки DVD-дискта, йөкләп алу өчен актив сылтамалар һәм (яки) хәтер флеш-картасында;

басма, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында (публикацияләр серияләре, махсус чыгарылышлар) һәм башка басма, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында юридик зат имзасы һәм мөһере белән (булган очракта) яисә авторның оригиналь һәм (яки) ксерокопиядә тәкъдим ителгән 1500 билгедән дә ким булмаган автор имзасы белән расланган һәм (яки) скан (фото) вариантта.

5.6. Конкурска тәкъдим ителгән конкурс эшләре рецензияләнми.

5.7. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр түбәндәге документлар пакетын тәкъдим итәләр:

1) әлеге Нигезләмәнең 5.5 пунктында күрсәтелгән форматта конкурс эше;

2) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән катнашу өчен анкета-гариза;

3) юридик затлар, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре өчен, юридик затлар буларак теркәлүчеләр түбәндәге документларны тапшыра:

салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык (салым түләүченең идентификация номеры);

юридик затның дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (төп дәүләт теркәү номеры);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләү турында боерык;

оештыру документлары;

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

ММЧны теркәү турында таныклык (күчермәсе) яки теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан - ММЧ өчен - Өземтә;

4) физик затлар - авторлар өчен:

паспорт яки аны алмаштыручы документ (яшәү (теркәү) урыны күрсәтелгән 2,3 битләре күчермәсе);

салым түләүченең идентификацион номеры;

мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында таныклык (СНИЛС күчермәсе);

әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык;

персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга персональ мәгълүматлар субъекты ризалыгы (әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында тәкъдим ителгән форма күрсәтелгән);

5) юридик зат булмаган ММЧ редакцияләре өчен:

ММЧны теркәү турында таныклык яки теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

"Массакүләм мәгълүмат чаралары турында" 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 20 статьясы нигезендә ММЧ редакциясенең яисә аның шартнамәсен алмаштыручы Уставының күчермәсе, әгәр массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе 10 кешедән ким булса;

баш мөхәррир вазыйфасына билгеләп кую турында боерык күчермәсе.

Әлеге пунктның 2-5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар электрон рәвештә pdf, jpeg һәм (яки) кәгазьдә тапшырыла.

5.8. Конкурска бирелгән документлар пакеты Татарстан Республикасы

Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан Мөрәҗәгать итүчедән алынганнан соң ике эш көне дәвамында теркәлә.

5.9. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) Мөрәҗәгать итүчеләр һәм Катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.10. Конкурс комиссиясе тарафыннан Конкурс эшләрен кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көн дәвамында нәтиҗәләр ясала һәм беркетмә төзелә, комиссия утырышы үткәннән соң ике эш көне дәвамында, аңа комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары кул куя.

5.11. Конкурска тапшырылган документлар, Катнашучыдан Конкурс эшен кире кайтару турында таләп алынганнан соң, 20 календарь көн дәвамында Катнашучыларга аларның таләбе буенча кире кайтарыла.

5.12. Заявкалар Конкурска йомгак ясаганнан соң өч ел дәвамында саклана.

6. Конкурс эшләрен үткәрү критерийлары

6.1. Конкурс эшен Конкурста катнашуга Оештыручылар тарафыннан гариза бирүчедән документлар алынганнан соң өч эш көне дәвамында әлеге Нигезләмәнең 5.4, 5.5, 5.7 пунктларында бәян ителгән таләпләргә туры килү-килмәүгә Конкурс эшләрен бәяләү нәтиҗәләре буенча рөхсәт яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

6.2. Гариза бирүченең конкурста катнашуына рөхсәт бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 5.4, 5.5 пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә әлеге Нигезләмәнең 5.7 пунктында каралган документларны гаризага тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

конкурста катнашу өчен гариза бирү вакытын үтәмәү;

конкурс эшләрен сурәттә яки тавыштагы хилафлыклар белән, шулай ук мәгълүматны бозып яки югалтуга китерә торган башка дефектлар белән бирү;

мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

Мөрәҗәгать итүчеләргә мондый карар кабул ителгәннән соң өч эш көне дәвамында Конкурста кертүдән баш тарту турында хәбәр ителә.

6.3. Конкурска кертелмәгән Конкурс эшләре, Конкурска документлар тапшыру вакыты кысаларында, билгеләнгән срокларда җитешсезлекләрне бетергәннән соң кабат Конкурска тапшырылырга мөмкин.

7. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

Конкурска кертелгән Конкурс эшләрен бәяләгәндә түбәндәге критерийлар кулланыла:

конкурс тематикасын чагылдыручы эчтәлек (0-10 балл);

үтемле куллану алымнары (0-10 балл);

Татарстан Республикасы халкы өчен публикацияләрнең һәм сюжетларның тәрбияви һәм иҗтимагый әһәмияте (0-10 балл);

экспертлар белән эшләү һәм интерактив куллану (0-10 балл);

материал бирү идеяләренең һәм алымнарының оригинальлеге (0-10 балл);

Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау турында серияле (ике һәм аннан күбрәк) материал булу (0-10 балл) (2 нче кушымтага туры килерлек итеп).

8. Конкурс комиссиясе

8.1. Кергән Конкурс эшләренә бәя бирү максатыннан Конкурс комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән конкурсны оештыручыларның һәм аларга буйсынган оешмаларның 6 вәкиленнән тора.

8.2. Комиссия эше белән рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаган очракта, Комиссия рәисе вазыйфалары Комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

8.3. Комиссия эше утырыш формасында башкарыла. Утырыш, әгәр анда комиссия әгъзаларының өчтән бер өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

8.4. Комиссия рәисе Комиссия утырышларының урынын, датасын һәм вакытын билгели, Комиссия утырышларында рәислек итә һәм Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү мәсьәләләре буенча Комиссия секретаренә йөкләмәләр бирә.

8.5. Комиссия секретаре түбәндәге функцияләрне башкара:

Конкурс эшләрен әлеге Нигезләмәнең 5.7 пунктында каралган документлар пакеты белән бергә кабул итә, терки һәм аларны саклауны оештыра;

бәяләү өчен Конкурс эшләрен Комиссия әгъзаларына җибәрә;

Комиссия утырышын оештыра, документлар әзерли һәм беркетмә төзи.

Комиссия секретаре Комиссия әгъзалары составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирмичә генә катнаша.

8.6. Әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә билгеләнгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары нигезендә Комиссия әгъзалары тәкъдим ителгән эшләрне бәяли. Һәр критерий буенча баллар саны 10 баллы шкала буенча билгеләнә (0-10).

8.7. Номинацияләрнең берсенә бер генә гариза бирелгән яки бер генә гариза да бирелмәгән очракта яки Конкурс Комиссиясе нинди дә булса номинация буенча «җиңүче» исемен бирмәү турында карар кабул иткән очракта, әлеге номинация буенча бүләккә бүлеп бирелгән акчалар тигез өлешләрдә башка номинацияләр буенча бүленә.

8.8. Иң күп балл җыйган катнашучы җиңүче дип таныла. Баллар тигез булганда, номинациядә призлы урын ике яки берничә катнашучыга бирелә. Шул ук вакытта тиешле призлы урын өчен каралган акчалар җиңүчеләр арасында тигез өлешләрдә бүленә.

8.9. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат утырыш беркетмәсенә кул куелганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://gosalcogol.tatar.ru), кулланучылар

хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы порталында (http://tatzpp.ru) ачык рәвештә урнаштырыла.

8.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

9. Финанслау

9.1. Конкурс үткәрү чараларын финанслау Программада каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

9.2. Конкурсның гомуми приз фонды 100,0 мең сум тәшкил итә.

9.3. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм түбәндәге акчалата призлар белән бүләкләнәчәк:

| Номинацияләр | Бүләкләнүчеләр саны | Суммасы, мең сумнарда |
|---|---|---|
| «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча басма массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы публикация» | 1 | 16 |
| «Татарстан Республикасында гражданнарның кулланучылар грамоталылыгын арттыру буенча массакүләм мәгълүмат чараларының иң яхшы редакциясе» | 1 | 16 |
| «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы интернет-басма» | 1 | 16 |
| «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы телесюжет (яки телетапшыру)» | 1 | 16 |
| «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктырту буенча иң яхшы радиосюжет (радиотапшыру)» | 1 | 16 |

9.4. Конкурста җиңүчеләр булмаган очракта, әмма югары нәтиҗәләр күрсәткән Катнашучылар (җиңүченең 80 һәм аннан да күбрәк баллары) өстәмә номинацияләрдә грамоталар һәм кызыксындыру призлары белән бүләкләнәләр:

| Номинацияләр | Бүләкләнүчеләр саны | Суммасы, мең сумнарда |
|---|---|---|
| «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктыртуда үҗәтлек өчен» | 1 | 5 |
| «Көчле әйтелде!» | 1 | 5 |
| «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктыртуда активлык өчен» | 1 | 5 |
| «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклау темасын яктыртуда оригиналь матерал өчен» | 1 | 5 |

Номинациядә баллар тигез булган очракта призлы урын ике яки берничә катнашучыга бирелергә мөмкин. Тиешле призлы урын өчен каралган акча чаралары тигез өлештә шул катнашучыларга бүленә.

9.5. Конкурска документлар тапшырганда, анкета-гаризада күрсәтелгән кредит оешмасындагы счетларга акчаларны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, Комиссия карары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә, Конкурска йомгак ясаганнан соң 15 календарь көн дәвамында гамәлгә ашыра.

## 10. Махсус шартлар

Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен закон нигезендә Конкурс эшләрен тәкъдим иткән Мөрәҗәгать итүчеләр һәм Катнашучылар җавап тота.

2023 елда кулланучылар
хокукларын яклау темасын иң
яхшы яктырту буенча
республика конкурсын үткәрү
турындагы Нигезләмәгә
1 нче кушымта

(Форма)

Кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика Конкурсында катнашуга анкета-гариза

Катнашучының исеме_______________________________________________
(оешманың исеме, катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Элемтә өчен телефон: ________________________________________________
e-mail________________________________________________________________
Эшчәнлек алып бару адресы ______________________________________
________________________________________________________________
Түбәндәге номинацияләрдә кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика Конкурсында катнашу турында хәбәр итәм

________________________________________________________________
(күрсәтергә кирәк):
Конкурс йомгаклары буенча бирелгән акчаларны күчерү өчен Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет реквизитлары:
________________________________________________________________
(Юридик затлар өчен: җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - җитәкче булганда), аның имзасы,
оешма мөһере (булганда); физик затлар өчен: мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда), имза

«___»_____________ Катнашучының имзасы

2023 елда Кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика Конкурсын үткәрү турындагы Нигезләмәгә
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау турында материаллар сериясе булу (ике һәм аннан да күбрәк)» конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

<table>
<tr><td rowspan="2">ЮК</td><td colspan="2">ӘЙЕ</td></tr>
<tr><td>Материаллар саны</td><td>Баллар</td></tr>
<tr><td rowspan="3">0</td><td>2 гә кадәр</td><td>1-3</td></tr>
<tr><td>2 дән 4 кадәр</td><td>4-7</td></tr>
<tr><td>5 һәм аннан да күбрәк</td><td>8-10</td></tr>
</table>

2023 елда Кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика Конкурсын үткәрү турындагы Нигезләмәгә
3 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртү, тапшыру һәм таратуга субъектның ризалыгы**

Мин,______________________________________________________________, __________________________________________адрес буенча яшим, шәхесемне раслаучы төп документ (паспорт) _____________________________________________________________________,

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә (алга таба – оператор) (Юридик адрес: 420107, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Х.Такташ ур., 94) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, шул исәптән туплау, системалаштыру, җыю, саклау, яңарту, үзгәртү, файдалану, тыю, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, Кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча конкурста катнашу максаты белән үз ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелгән шәхси мәгълүматларның исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртелә торган персональ мәгълүматлар исемлеге | фамилиясе, исеме, атасының исеме*, туу датасы һәм урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары (документ төре, аның сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм бирелгән вакыты), яшәү урыны, телефонның контакт номеры, электрон почта адресы, эш урыны һәм биләгән вазыйфасы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет турында белешмәләр |

Әлеге килешү кул куелганнан соң 1 (бер) ел гамәлдә.

Шәхси мәгълүматлар субъекты, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, үз шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алырга хокуклы.

Әгәр дә персональ мәгълүматларны саклау персональ мәгълүматларны эшкәртү максатлары өчен кирәк булмаса, шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктатырга яки юк итәргә (әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарыла икән), оператор персональ мәгълүматларын эшкәртүне туктатырга яки туктатуны тәэмин итәргә тиеш (әгәр персональ мәгълүматларны саклау персональ мәгълүматларны эшкәртү максатыннан башкача таләп ителмәсә), шәхси мәгълүматларны юк итәргә яки аларны эшкәртүне туктатуны тәэмин итү (әгәр персональ

мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарыла икән), күрсәтелгән чакыртып алу датасыннан утыз көннән дә артмый. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ мәгълүматларны юк итү мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый шәхси мәгълүматларны блоклауны башкара яки аларны блоклауны тәэмин итә (әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарыла) һәм шәхси мәгълүматларны алты айдан да ким булмаган вакытта юкка чыгаруны тәэмин итә.

_______________________________________________________________/_____________
_
(Ф.И.А исеме* һәм персональ мәгълүматлар субъекты имзасы)

__________________
(Дата)

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

2023 елда Кулланучылар
хокукларын яклау темасын иң
яхшы яктырту буенча
республика Конкурсын үткәрү
турындагы Нигезләмәгә
4 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

**Шәхси мәгълүматларны тарату өчен, субъект тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә**

**ризалык**

Мин,

____________________________________________________________________,
(фамилия, исеме, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)

_____________________________________________________________________
(почта адресы)

_____________________________________________________________________
(электрон почт адресы)

_____________________________________________________________________
(телефон номеры)

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 10.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә (алга таба - оператор) (ОГРН 1021602865239, ОКТМО 927010001, ОКПО 42151664), Юридик адрес: 420107, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Һ.Такташ ур., 94, Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында кулланучылар хокукларын яклау темасын иң яхшы яктырту буенча республика Конкурсында катнашу өчен үземнең шәхси мәгълүматларымны таратуга (тапшыру, бирү) рөхсәт бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге

| № п/п | Персональ мәгълүматлар | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | Юк |
| Гомуми персональ мәгълүматлар | | | |
| 1. | Фамилия, исеме, атасының исеме (булган очракта) | | |
| 2. | Туган көне, ае, елы, урыны | | |
| 3. | Шәхесне раслаучы документ реквизитлары (документ төре, аның сериясе һәм номеры, кем һәм кайчан бирелгән) | | |
| 4. | Яшәгән урыны | | |
| 5. | Телефон номеры | | |
| 6. | Электрон почта адресы | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Эш урыны һәм тоткан вазыйфасы | | |
| 8. | Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп турында мәгълүмат | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар билгеләнә торган шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге

| N п/п | Персональ мәгълүматлар | Эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. (Персональ мәгълүматларның категориясе) | | |
| | (Персональ мәгълүматларның исемлеге) | |

**Искәрмә.** Әлеге кыр шәхси мәгълүматлар субъекты теләге буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүне башкаручы оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.

Шартлар һәм тыюлар оператор тарафыннан чикләнмәгән яки билгеле бер даирәгә шәхси мәгълүматларны тарату һәм (яки) бирү буенча гамәлләрне чикләү яки тыюны күздә тота.

Өстәмә килешүдә шәхси мәгълүматлар персональ мәгълүматларны эшкәртүне башкаручы оператор тарафыннан бары тик аның эчке челтәре аша гына, бары тик катгый билгеле хезмәткәрләр өчен генә, яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, яки алынган персональ мәгълүматларны тапшырмыйча гына тапшырыла ала торган шартлар күрсәтелергә мөмкин.

Операторның чикләнмәгән даирәгә керү мөмкинлеге бирелә торган мәгълүмат ресурслары һәм шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматлары белән бүтән гамәлләр: https://gosalcogol.tatarstan.ru/

Әлеге килешү ________________________________________кадәр дәвам итә
(килешүнең тәгәл гамәлдә булу вакытын күрсәтергә)

Шәхси мәгълүматлар субъекты, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, үз шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алырга хокуклы.

Әгәр дә персональ мәгълүматларны саклау персональ мәгълүматларны эшкәртү максатлары өчен кирәк булмаса, шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктатырга яки юк итәргә (әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарыла икән), оператор персональ мәгълүматларын эшкәртүне туктатырга яки туктатуны тәэмин итәргә тиеш (әгәр персональ мәгълүматларны саклау персональ мәгълүматларны эшкәртү максатыннан башкача таләп ителмәсә), шәхси мәгълүматларны юк итәргә яки аларны эшкәртүне туктатуны тәэмин итү (әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарыла икән), күрсәтелгән чакыртып алу датасыннан утыз көннән дә артмый. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ мәгълүматларны юк итү мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый шәхси мәгълүматларны

блоклауны башкара яки аларны блоклауны тәэмин итә (әгәр персональ мәгълүматларны эшкәртү оператор кушуы буенча эш итүче башка зат тарафыннан башкарыла) һәм шәхси мәгълүматларны алты айдан да ким булмаган вакытта юкка чыгаруны тәэмин итә.

__________________________________________________________/__________/

(Ф.И.А исеме* һәм персональ мәгълүматлар субъекты имзасы)

«___» __________20___г.

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә